Рус Әшнәгеавыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2016 елның 16 феврале Рус Әшнәге авылы № 4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында»2015 елның 21 июлендәге 7 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәлләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3,5 өлеше нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Рус Әшнәгеавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авылы, Профсоюз урамы, 7а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгы В.Х.Хаҗиев